| ЛЕНИНОГОРСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1.02.2022 г.Лениногорск № 75

Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре территориясендә муниципаль контроль турында Совет карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Лениногорск шәһәр Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре территориясендә муниципаль урман контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 30 сентябрендәге 58 номерлы Лениногорск шәһәр Советы карары,

«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 16 декабрендәге 69 номерлы Лениногорск шәһәр Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Муниципаль контроль өчен индикатив күрсәткечләрне кушымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов

Лениногорск шәһәр Советының
2022 елның
1 февралендәге 75 карарына кушымта

Муниципаль контрольнең индикатив күрсәткечләре исемлеге

1) хисап чорында үткәрелгән планлы тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны;

2) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны;

3) мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга контроль объектының туры килүен ачыклау яисә мондый параметрлардан, хисап чорыннан контроль объектын тайпылдыру нигезендә хисап чорында үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

4) хисап чорында үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларның гомуми саны;

5) хисап чорында үткәрелгән КНМның һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек белән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитларның саны;

8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;

9) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

10) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында тикшерү (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) прокуратура органнарына хисап чорында прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тарткан контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

15)хәвеф-хәтәр категорияләренә кертелгән исәпкә алынган контроль объектлары саны хисап чоры ахырына һәр риск категориясе буенча;

16)хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затларның исәпкә алынган саны;

17)хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

18)хисап чорында контрольлек итүче затлар тарафыннан судка кадәр тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

19)хисап чорында контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләр саны;

20) тикшерү (күзәтчелек) органы карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгару турында яисә контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) хисап чорында гамәлдә түгел дип тану турында карар кабул ителгән контрольлек итүче затлар тарафыннан судка кадәр тәртиптә бирелгән шикаятьләр саны;

21) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны;

22)контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны, алар буенча карар кабул ителгән;
хисап чорында бирелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында;

23) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыруга таләпләрне тупас рәвештә бозып үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип табылган һәм (яисә) юкка чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.